| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 февраль г.Бугульма № 160

**Торак сатып алуга Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210 номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. Торак сатып алуга Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта буенча расларга.
2. Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең "Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, "Маяк" җитештерү берләшмәсендәге авария һәм аларга тиңләштерелгән затларга радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга Дәүләт торак сертификатын исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 12 апрелендәге 406 номерлы карары, “Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм мәҗбүри күченүчеләргә торак бирүгә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2016 елның 12 апрелендәге №408 крары, “Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 13 октябрендәге 1116 номерлы карары, "Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, "Маяк" җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга Дәүләт торак сертификатын исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 12 апреле №406 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны тормышка ашыруда контрольне Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад үсеше сораулары буенча урынбасары М.Р. Болгаковка йөкләргә.

А.Р. Галиуллин